# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Биләр авыл җирлеге Биләр авыл торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

**2022 елның 14 октябреннән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 14 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Биләр авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге территориясендәге Биләр авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1) Садовая урамы, Ленин урамы, Бутлеров урамы, җирлек эчендәге юлларны төзү (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эш хакын килешү буенча түләү)
2) җәйге чорда грейдерлау һәм территорияне чабу (
ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
3) кышкы чорда җирлек эчендәге юлларны чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
4) тракторны карап тоту (запас частьләр сатып алу, ЯММ, хезмәткә түләү);
5) күмү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (авария хәлендәге агачларын кисү һәм җыештыру, килешү буенча түләү);
6) урам утларын карап тоту (лампаларны ремонтлау, сатып алу);
7) суүткәргечне карап тоту, су башнясын күчерү.
8) зур күләмле чүпләрне җыю,чыгару (айга бер тапкыр ) .

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Биләр авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 1608 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 842 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 831 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 11 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Биләр авыл җирлегендәге Биләр авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Биләр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Биләр авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокլы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1) Садовая урамы, Ленин урамы, Бутлеров урамы, җирлек эчендәге юлларны төзү (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эш хакын килешү буенча түләү)

2) җәйге чорда грейдерлау һәм территорияне чабу (
ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3) кышкы чорда җирлек эчендәге юлларны чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

4) тракторны карап тоту (запас частьләр сатып алу, ЯММ, хезмәткә түләү);

5) күмү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (авария хәлендәге агачларын кисү һәм җыештыру, килешү буенча түләү);

6) урам утларын карап тоту (лампаларны ремонтлау, сатып алу);

7) суүткәргечне карап тоту, су башнясын күчерү.

8) зур күләмле чүпләрне җыю,чыгару (айга бер тапкыр ) .

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Биләр авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Биләр авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Биләр авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Биләр авыл җирлеге башлыгы Хәбибуллин Г.Г.